# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Түбән Табын авыл җирлегенең Түбән Табын торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 ел 15 ноябрь** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 2023 нче елның 15 ноябрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Сез 2024 нче елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Түбән Табын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**I. <u>Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:</u>**
1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту - АҖ буенча
2) Янгын сүндерү өчен сыйдырышлы савыт сатып алу - АҖ буенча

**II. <u>Урам яктырту җайланмасы, ремонт:</u>**
1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау - АҖ буенча
2) Лампалар сатып алу - 15 данә - АҖ буенча

**III. <u>Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:</u>**
1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда - АҖ буенча
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда - АҖ буенча
3) Мәктәп урамы юлларын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу
4) Трактор өчен кар эттергеч җайланмасы сатып алу - АҖ буенча
5) Тактор өчен печән чапкыч машина сатып алу - АҖ буенча
6) Юл кырындагы үләнне чабу - АҖ буенча
7) Трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алу - АҖ буенча

**IV. <u>Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:</u>**
1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу - АҖ буенча

**V. <u>Ритуаль хезмәтләр һәм күму урыннарын карап тотуны оештыру</u>**
1) Зиратта үлән чабу
2) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу.
3) Кул печән чапкычы сатып алу – 2 (ике) данә – АҖ буенча

4) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
5) Койма-киртәләрне ремонтлау.»

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 120 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 75 кеше, бу 62,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 75 кеше тавыш бирде; 0 кеше "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Түбән Табын торак пунктында халык җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. 2024 нче елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Түбән Табын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3.Түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

**I. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**
1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту - АҖ буенча
2) Янгын сүндерү өчен сыйдырышлы савыт сатып алу - АҖ буенча

**II. Урам яктырту җайланмасы, ремонт:**
1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау - АҖ буенча
2) Лампалар сатып алу - 15 данә - АҖ буенча

**III. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**
1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда - АҖ буенча
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда - АҖ буенча
3) Мәктәп урамы юлларын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу
4) Трактор өчен кар эттергеч җайланмасы сатып алу - АҖ буенча
5) Тактор өчен печән чапкыч машина сатып алу - АҖ буенча
6) Юл кырындагы үләнне чабу - АҖ буенча
7) Трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алу - АҖ буенча

IV. Җирлек территориясен төзеклендерүне оештыру:
1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу - АЖ буенча

V. Ритуаль хезмәтләр һәм күму урыннарын карап тотуны оештыру
1) Зиратта үлән чабу
2) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу.
3) Кул печән чапкычы сатып алу – 2 (ике) данә – АЖ буенча
4) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
5) Койма-киртәләрне ремонтлау.»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы Р.Ш. Кыяметдинов